КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 13 апрель г.Казань № 253

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын бирү тәртибе турында» 2007 ел, 20 сентябрь, 475 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын бирү тәртибе турында» 2007 ел, 20 сентябрь, 475 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 15 ноябрь, 936 нчы; 2013 ел, 10 июнь, 395 нче; 2013 ел, 2 ноябрь, 836 нчы; 2016 ел, 19 апрель, 239 нчы; 2017 ел, 28 июнь, 447 нче; 2019 ел, 30 апрель, 372 нче; 2019 ел, 30 декабрь, 1273 нче; 2020 ел, 28 гыйнвар, 41 нче; 2020 ел, 17 март, 193 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.8.1 пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

«в» пунктчасында «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органының» сүзләренә алмаштырырга;

4.8.2 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә, «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына» сүзләрен «республика башкарма хакимият органына» сүзләренә алмаштырырга;

6.1 пунктның беренче абзацында «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» сүзләрен «Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, алар арасыннан затларның торак урынына хокукларын гамәлгә ашыру турында» сүзләренә алмаштырырга;

6.2 пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

6.3 пунктта:

«Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Махсуслаштырылган торак урыны наемы шартнамәсенең гамәлдә булу срогы махсуслаштырылган торак урыны наемы шартнамәсе төзелгән зат инициативасы буенча әлеге зат тарафыннан вәкаләтле органга мондый шартнамәнең гамәлдә булу срогын кыскарту турында гариза тапшырылган датага карата «Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә гарантияләре турында» 1996 елның 21 декабрендәге 159-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы $6^2$ пунктында күрсәтелгән вакыйгалар җыелмасы булганда кыскартылырга, әмма иң күбе ике елга кыскартылырга мөмкин.»;

6.5 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин